ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# "Татарстан Республикасы Дәүләт Советының профессиональ даими нигездә эшләүче депутатлары саны турында" Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына һәм "Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында" Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 30 октябрендә
кабул ителде

## 1 статья

"Татарстан Республикасы Дәүләт Советының профессиональ даими нигездә эшләүче депутатлары саны турында" 2003 елның 22 сентябрендәге 36-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы 2003, № 9 (I өлеш), түбәндәге эчтәлектәге җөмлә өстәп, үзгәреш кертергә: "Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары (урынбасарлары) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары нигезендә үз вәкаләтләрен төп эшчәнлектән аерылмыйча гамәлгә ашыра ала (алалар).".

## 2 статья

"Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында" 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 2 пунктында "Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе" сүзләреннән соң ", профессиональ даими нигездә эшләүче" сүзләрен өстәргә;

2) 19 статьяның 1 пунктында:

а) беренче абзацта "Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисеннән" сүзләреннән соң ", профессиональ даими нигездә эшләүче" сүзләрен өстәргә;

б) икенче абзацта "Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенә" сүзләреннән соң ", профессиональ даими нигездә эшләүче" сүзләрен өстәргә.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 20 ноябре
№ 88-ТРЗ